| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2019 г.Зеленодольск № 455

Зеленодольск муниципаль район Советының 2018 елның 27 декабрендәге 357 номерлы карары белән расланган (2019 елның 26 апрелендәге 385 номерлы карарында кертелгән үзгәрешләр белән) Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты 2019 елга Зеленодольск муниципаль районын хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) тәкъдим иткән үзгәрешләрне карап, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. «2019 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2018 елның 27 декабрендәге 357 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән (2019 елның 26 апрелендәге 385 номерлы карарында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, 2019 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган башка мөлкәт исемлеге» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Исеме | **Мөлкәтнең урнашу урыны** |
|---|---|---|
| 1 | Мәйданы 723,1кв.м булган бакча-ясле, җир мәйданы 4794 кв.м. | **Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Бишнә авылы, Школьная ур., 6а** |
| 2 | «Лифт» Зеленодольск предприятиесе» ААҖ акцияләре пакеты күләме 32775 данә яки устав капиталының 25% . | |

2. 2019 елның 26 апрелендәге 385 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары «Зеленодольск муниципаль районы Советы 2018 елның 27 декабрендәге 357 номерлы карары белән расланган 2019 елга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү турында» үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Россия Федерациясенең рәсми сайтында торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен (http://www.torgi.gov.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **Э.Р. Кадникова**